
Банк России

# ҮЗЕГЕЗНЕҢ ГАДЖЕТЛАРЫГЫЗНЫ ВИРУСЛАРДАН НИЧЕК САКЛАРГА

**Вируслар:**

- сезнең җайланмаларга еректан файдалану мөмкинлеген ачалар
- мобиль һәм онлайн-банкларның логин һәм парольләрен урлыйлар
- хәбәрләрдән яшерен кодларны тотып алалар

**Бу мәгълүматларны алып, киберҗинаятьчеләр сезнең банк исәпләреннән барлык акчаларыгызны урларга мөмкиннәр**



## Җайланманың вируслы икәнен НИЧЕК АҢЛАРГА?

- туктап кала, яңадан эшли башлый яки сүнә
- кушымталар эшен үзе тәмамлый
- калкып чыгучы тәрәзәләрне күрсәтә
- хәтер күләмен югалта

## Җайланмага вирус эләккән БУЛСА НИШЛӘРГӘ?

- **банкка шалтыратыгыз** һәм җайланмада кулланылган барлык карталарны, онлайн һәм мобиль банкка керү юлларын ябуны сорагыз
- **сервис үзәгенә мөрәҗәгать итегез,** гаджетны дәвалауны сорагыз
- **яңа карталар ясатыгыз,** онлайн-банкның логинын һәм паролен алыштырыгыз һәм банк кушымтасын яңадан урнаштырыгыз

## Җайланманы вирустан НИЧЕК САКЛАРГА?

- **антивирус кулланыгыз** һәм аны даими яңартып торыгыз
- **таныш булмаган кешеләрнең сылтамалары** буенча күчмәгез, аларның үтенече буенча программалар урнаштырмагыз, чит флешкалар кулланмагыз
- **кушымталарны тикшерелгән** чыганаклардан гына алыгыз
- **җайланманың операцион системасын** яңартыгыз
- барлык кеше куллана торган wi-fi челтәрләреннән **сакланыгыз**

Гаджетларны саклау турында тулырак **fincult.info** да укыгыз

**Финанс культурасы**